**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**«ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИСКЕ АБДУЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ»**

# КАРАР

«29» апрель 2023 ел № 27/1

**«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында нигезләмәне раслау хакында» «Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2022 елның 28 ноябрендәге 20/2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 31 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 январендагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 июлендәге 273-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы федераль законнар, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы авыл җирлеге уставы нигезендә, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында нигезләмәне раслау хакында» «Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2022 елның 28 ноябрендәге 20/2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 статьяның 3 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» (алга таба – Татарстан Республикасы Рәисе) сүзләренә алыштырырга;

1.2. 18 статьяның 1 пункты «б» пунктчасында «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алыштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе Р.Х.Сафина

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «СТАРОАБДУЛОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ТУКАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА «ИСКЕ АБДУЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
ОГРН 1051605001097
Р 05-1180209
СОВЕТ СТАРОАБДУЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1639009785